КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 декабрь г.Казань № 1295

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 639 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 364 нче; 2018 ел, 16 май, 372 нче, 2021 ел, 25 март, 168 нче, 2022 ел, 19 апрель, 368 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Совет составыннан А.М.Терентьевны чыгарырга;

Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Мөхәрләмов Руслан Роберт улы | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сафин Ленар Ринат улын | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректорын (килешү буенча) |

Сәфәров Әсгать Әхмәт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы рәисе (Иҗади берлек), Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы чакырылыш депутаты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин